СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**28 апрель, 2026 ел** **№ 73**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2012 елның 12 декабрендәге 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 15 августындагы 435 карарын үз көчен югалткан дип тану турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 1743 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Каенлык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2026 елның 08 апрелендәге 652/о номерлы боерыгын раслауга бәйле рәвештә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2012 елның 12 декабрендәге 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 15 августындагы 435 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмат белән тәэмин итү» дәүләт мәгълүмат системасындагы белешмәләрне территориаль планлаштыруның элек кабул ителгән тиешле документлары буенча урнаштырылган документларның статусларын үзгәртү өлешендә актуальләштерү эшен тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов